**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**«ӘҖМӘКӘЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»**
**МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ СОВЕТЫ**

«11» апреля 2024 ел № 39/1

**КАРАР**

**«Җирле салымнар буенча недоимканы, пенялар һәм штрафлар буенча бурычларны түләтүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләү турында» Әҗмәкәй авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Советының 2020 елның 14 октябрендәге 2/4 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясе Салым кодексының 59 статьясы 3 пункты, «Түләтүгә өметсез дип танылган недоимканы һәм пенялар, штрафлар һәм процентлар буенча бурычларны юкка чыгару тәртибен һәм Недоимканы, пенялар, штрафлар һәм процентлар буенча бурычны түләтүгә өметсез дип тану шартларын раслаучы документлар исемлеген раслау турында» Россия Федераль салым хезмәтенең 2019 елның 2 апрелендәге ММВ-7-8/164@ номерлы боерыгы нигезендә

**КАРАР БИРДЕ:**

1. «Җирле салымнар буенча недоимканы, пенялар һәм штрафлар буенча бурычларны түләтүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләү турында» Әҗмәкәй авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Советының 2020 елның 14 октябрендәге 2/4 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1 пунктка түбәндәге эчтәлектәге «д)» пунктчасын өстәргә:

«махсус хәрби операциядә катнашучыларның җир салымы һәм мөлкәтенә салым буенча».

2. Әлеге карар мәгълүмат стендларында, ТР рәсми хокукый мәгълүмат порталында һәм районның рәсми сайтында урнаштырылган көннән бер ай вакыт узганнан соң үз көченә керә.

3. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны Әҗмәкәй авыл җирлеге Советының законлылык һәм хокук тәртибе буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Муниципаль берәмлек Башлыгы,
Совет Рәисе О.А. Чекушкова